**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**АККҮЗ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

423744, Аккүз авылы,
Үзәк ур., 1 нче йорт.
Тел.3-44-42

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА АККУЗОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423744, село Аккузово,
ул. Центральная,дом 1,
Тел. 3-44-42

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«31» октября 2023 года** **№ 2**

**Актаныш муниципаль районы Аккуз авыл җирлегенең Чишмә, Меңнәр авылларында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына ярашлы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Актаныш муниципаль районы «Аккуз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 25.1 статьясы Аккуз авыл җирлеге башлыгы:

Карар итә:

1. Актаныш муниципаль районы Аккуз авыл җирлегенең Чишмә,Меңнәр авыллары территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2023 елның 10 ноябрендә 18.00 сәгатькә билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: Сез 2024 елда җирлек чикләрендә яшәүче 18 яшькә җиткән һәр гражданнан, җирле референдумда катнашуларына һәм тавыш бирүдә белдергән мөнәсәбәтләренә карамастан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1 Төркем инвалидларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым түләүне кертүгә ризамы,«Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында «Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Аккуз авыл җирлеге территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнары һәм аларның гаилә әгъзалары, аларның саны җирлектә яшәүчеләрнең гомуми санының 30 процентыннан артмаска тиеш, һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләр:

1.Торак пункт чикләрендә юлларны һәм юл кырыйларын ремонтлау ;

2.Торак пункт чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру,сууткәргеч челтәрләрен һәм чишмәләрне тоту, документаль рәсмиләштерү.

3. Торак пункт территориясен төзекләндерүне оештыру.

4. Торак пунктта яшәүчеләрнең күпләп ял итү өчен шартлар тудыру һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру, шул исәптән гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буйларына ирекле керүен тәэмин итү.

"ӘЙЕ" "ЮК"

1. Гражданнар җыенын Татарстан Республикасы, Актаныш районы,Меңнәр авылы, Үзәк урам, 70 йорт адресы буенча гражданнар җыенын уздырырга.
2.Актаныш муниципаль районы Аккуз авыл җирлеге башкарма комитетын Гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.
3. Әлеге карарны Аккуз авыл җирлеге мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында игълан итәргә.
4. Башкаруны контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Аккуз авыл җирлеге башлыгы: Г.И.Имамова